1

Мәсүдә Шәмсетдинова

истәлекләр.

www.tatars.com

**Түбән Мактамада совет власте төзү еллары. Сәнәк сугышы. Колхоз чоры.**

Совет властен төзү барлык совет халкына бик күп авырлыклар белән яулап алынган кебек үк Түбән Мактамада да үзеннән үзе җиңел генә килеп чыкмады. Ул заманнарда Элмәт волосте Бөгелмә өязенә (Революциягә кадәрге Россиядә һәм 1929 елга кадәр СССРда: губернаның бер состав өлеше булган административ-территориаль берәмлек) кергән Түбән Мактама авылы олы юл өстенә, ягъни Казан-Оренбург юлына урнашкан авыл иде. Олы юл буенда булу сәбәпле Мактама халкына ул елларда күп кыенлыкларны кичерергә туры килде. Туган туганга, күрше- күршегә дошман булды. Бер авыл аклар ягында булса икенчесе кызыллар ягында иде. Авыл белән авыл, урам белән урам, туган белән туган бер-берсенә сугыш белән чыкты. Кодаш, Карабаш авылларында төпләнеп калган алар отряды Түбән Мактамага да килеп керәләр. Алар Мактамадан олы юл буйлап Акташ ягына юл тоталар. Акташ янында кызыллар тарафыннан җиңелеп тагын Түбән Мактамага чигенәләр. Шулай итеп авылга я аклар килеп талый, Я кызыллар талый. Акылы, зиһене белән дан казанган Түбән Мактама халкы бик зур аптырашта кала. Революциянең авырлыгын үз җилкәсендә үткәрә. 1918 елның февраль башларында Сарман, Кичуй һәм Ельховой ягыннан сәнәклеләр фетнәсе килеп тошә. Сәнәклеләр шымчы әләкләве буенча Түбән Мактама кешесе Шиһапов Сарыйм дигән кешене канга батырып кыйныйлар. Авылның бер тәвәккәл бәндәсе Мөхәммәди Солдат үз авторитеты белән Шигаповны үлемнән коткарып кала. Шигапов Сарыйм ул елларда Элмәттә оешкан газетада редактор булып эшли. Авылда сәнәкчеләр беренче активларны эзәрлекли башлыйлар. Түбән Мактамада гына түгел тирә-як авылларда сәнәкчеләр бунты көчәя. Ярсыган ике яклы халык гомердә татарда булмаган нәфрәт белән берсе берсен җәзалап үтерә. Берсеннән берсе фәҗигалы вакыйгалар озак еллар мактамалылар хәтерендә уелып кала. Менә шул хәтирәләрнең берсе: беренче совет мәктәбен ачып җибәрүчеләрдән Гарифуллин Габделгазиз исемле кеше шул көннәрдә хатыны белән Карабашка туганнарына китә. Менә шунда Карабаш авылының хәзрәт ялчылары - сәнәкчеләр бу кешене тотып алалар. Хатынын авырлы килеш кышкы чатнама суыкта Зәй бәкесенә салып үтерәләр. Гарифуллин үзе яланөс, яланаяк

хәзрәт ялчылары - сәнәкчеләр бу кешене тотып алалар. Хатынын авырлы килеш кышкы чатнама суыкта Зәй бәкесенә салып үтерәләр. Гарифуллин үзе яланөс, яланаяк Зәй буйлап әрәмә арасыннан Карабаштан Габдерахманга таба йөгерә. Габдерахман тегермәненә җиткәндә катып үлә. Сафуанов Беренче комсомоллар: Исрафилов Әхмәдулла, КПСС әгъзаларыннан Нәбиуллин Габдулла, Нәҗметдинов Хафиз, Залятов Барый (Марс Залятовның әтисе Шәехразый абзыйның абыйсы) Гайнетдинов Һадыйлар, Сафуанов Гатуфлар булалар. Авылда Совет власте барлыкка килгәч беренче авыл советы председателе булып Салихов Зыятдин билгеләнә, ә аның секретаре булып Мөшәрәпов Ярләхмәтме, Ярмөхәммәтнеме (?) билгелиләр. Салихов Зыятдинга күп еллар эшләргә насыйп булмый, аны чәнчеп үтерәләр.

1929 елларда авылда колхоз оештыру чоры башлана. Бу чордада колхозга карата халыкта төрле фикерләр, төрле карашлар була. Бүген колхозга алыгыз, дип, гариза бирәләр һәм малларын колхоз фермасына тапшыралар, иртәгәсен иртән үк маллар артыннан килеп җитеп, гаризаларын ертыпаталар. 1930 ел башларында колхоз төзелә. Аның беренче председателе булып Залятов Барый сайлана. Колхозга беренче булып керүчеләр: Нәбиуллин Габдулла, Шәйһиморатова Хөпъямал, Садретдинов Камил, Сафин Муллагали. Сәләмәтлеге какшагач. Залятов Барый эшеннән китә, исәп-хисапка оста булганга аны счетовод итеп куялар һәм колхоз председателе итеп Нәбиуллин Габдулланы сайлыйлар (Татэксның генеральный директоры Хәмит Кавиевның бабасының бабасы). Авыл советы председателе булып Фәйрушин Мәрданша билгеләнә. Колхоз экономикасын ныгыту һәм колхоз оештыруда актив катнашучылардан Салихов Фалях, Шакирҗанов Ахунҗан, Залятов Барый, Нәбиуллин Габдулла. Колхоз ныгый. Колхоз үсә барган саен техник белемле кешеләр кирәк була. Бу яктан мактамалылар үзләрен сынатмый. Әлмәт районында беренче шофер булып Мактама кешесе Карамулла Яруллин була. Колхозга беренче тракторга утырып кайтучы Нәбиуллин Рәхматулла. 1938 елда Түбән Мактамага беренче полуторка кайта. Моның шоферы булып Нургалиев Мөнир утыра. Ватан сугышына ул колхоз машинасына утырып китә һәм һәлак була. Бөек Ватан сугышы алдыннан авыл советы председателе итеп Гатауллин Габделхак билгеләнә, колхоз җитәкчесе булып Шакирҗанов Ахунҗан сайлана. 1939 елда авылны төзекләндерү, үзгәртү кертү өчен генераль план төзелә. Бу план нигезендә Инеш белән

Пушкин урамы арасындагы 5 хуҗалыкны күчереп клуб, колхоз идарәсе, сельсовет һәм библиотека салынырга тиеш була. 1940 елда клуб һәм библиотека биналарын бурап, бураларын күтәрептә куялар. Революция иләгеннән үткән авыл инде матур гына яшәп киттем дигән дә Ватан сугышы хәсрәтенә кереп чума.
Габдулла мулла хәтирәләреннән

Гыбрәтле булса да йөргән җир, сагындыра туган ил...

Сугышка киткән батырларның һәрберсе язмышы турында романнар язып булыр иде. Күп серияле кинолар төшереп булыр иде. 300 ил лачыны, 300 хәсрәтле язмыш. 23 бөртек энҗе - 23 бөртек сугыш ветераны бүгенге көндә исәннәр. Хәтирәләр күзләрдән яшь китерә:
Колхоз председателе Шакирҗанов Ахунҗан һәлак була. Сельсовет председателе Гатауллин Габделхак совет армиясендә элемтәче хезмәт итә. 1942 елның 25 июлендә Харьков астында каты сугышлардан соң чолганышта калалар, 26 кеше чолганышта калалар, 1,5 чолганыштан чыга алмыйча йөргәндә бер елга буенда немец солдатлары пленга алалар. Үзләре араснан берсе ул коммунист дип әләкли, Гатауллин Харьков-2 төрмәсендә ята. Соңыннан аларны концлагерьгә озаталар. 85 мең кеше арасыннан 250 кеше исән кала. Соңыннан әсирләр Львовка күчерелә, Польша белән Чехословакия чигендә урнашкан концлагерьгә ябыла. 1944 елда Франциягә алып китәләр. Пленда булган өчен үз илендә күргән хәсрәтләрне, гарьләнү хисләрен алар тик үзләре генә белә. Шулай Европаларны гизеп йөргән Түбән Мактама егетләре сугыш кырыннан ярым-ярты, пыяла күзле, кулсыз, аяксыз булып җырмачланган ил егетләре ачлыктан шешеп беткән аналары, хатыннары янына килеп егылалар. Кайберләре кайта.. ә күпләре эзсез юкка чыга. Шуларның берсе Марс Залятовның әтисе Шәехразый Залятов.

Здесь копия документа-ответа на запрос Марса Залятова об отце, что Ш. Залятов погиб на 68 км недалеко от Москвы.

Шәехразый Залятов кызы Мөхтәрәмә ..... хәтирәләреннән.
«Безнең ике яктан да бабалар Ялалетдин исемлеләр. Эниебез Вәсилә бик иркә кыз булган, чөнки аның әтисе

www.tatars.com

Ялалетдин бабай бик уңган булган, үз зиһене, үз көче белән мал тапкан, гаиләсен караган. Мин аның яраткан оныкларыннан иң яратканы идем, картаеп беткәч тә кәкре таягы белән чабуымнан өстери иде. Бик укымышлы карт булган ул үз заманы өчен. Китаплары бик күп иде. Ничек саклап кала алгандыр ул теге заманнарда. Минем укыганымны тыңларга бик ярата иде. Менә шушы ике Ялалетдин бабайларыбыз сүз куешып әти белән инәйне туйлап өйләндергәннәр. Элекке заманнарда Түбән Мактаманың хәллерәкләре, кызның әти-әнисе кияүләшергә, кәләшләшергә мөмкинчелек биргәннәр. Кайвакыт хатын-кыз әтисе йортында баланы тапмыйча иренең йортына күчмәгән. Шул гадәтне саклап инәй белән әти Ялалетдиннар бабайларда бер ничә атна кадерләнгәннәр. Эмма озак кадерләнә торган чаклар узган инде ул вакытларда. Иске гадәтләрне тотасыз дип башың китүе дә бар. Эти безнең Барый абыйсы кебек үк авыл тормышында бик тырышлык күрсәткән кеше. Аның булдыклылыгын күргән җитәкчеләр бер авылдан бер авылга я председатель, я сельсовет председателе, я милиционер итеп билгелиләр. Бер вакыт этине Туктар авылына колхоз председателе итеп куйдылар. Хәтердә уелып калган: Безгә бер кечкенә өй бирделәр, шул өйнең ишек алды кып-кызыл җир җиләге иде. Этинең эштән кайтуына чәй белән эчәргә дип инәй шул җиләкләрне җыядыр ие. Бер вакыт эти инәемә: син колхоз председателе хатыны, матур киен, дип, кызыл кофта, зәңгәр юбка алып кайтты. Колхоз председателе хатыны булсам да мин марҗа түгел ич кофта белән юбка кияргә дип, инәй шул юбка белән кофтаны кимәде. Йомшак булсада бик үзсүзле, горур иде инәй. Кешегәдә бирмәде, эти үпкәләр, дип, кимәде дә, тәрәзә төпләрендә кояш нурында йөреп ул кофта белән юбка искерде. Эти Нәдердәдә, Элмәттә дә эшләде. Матур атларга тарантас җигеп,яшел милиция күлмәкләрендә өйгә кайтып керер ие дә, мине эзли башлар ие. Мине тапмыйча ашарга утырмас ие. Миңа кадәр көтеп алган ике кызлары үлгәч, кадерле булганмындыр инде. Тезенә утыртып сүкертә иде, сөя иде. Бәрәңге бакчасында без күрше кызлар белән төрле уеннар уйный идек. Эмма иң яратканыбыз бәрәңге сабаклары арасына сырган юрганнарны, өйдә нинди матур нәрсә бар декорация өчен, шулар белән театр куябыз. Эти тамашачы ролендә. Эзерләнеп бетмичә мине чакырмагыз, артистлар алай эшләми дип безгә таләп куя иде. Инәй этине орыша: Бөтен юрган-мендәрләремне балчыкка катырып бетерәсез, Үзең балалардаңда болаерак, дип.



www.tatars.com

Марс Мактамабашта туды. Инәй авырый башлагач мине өйдән чыгарып җибәрделәр. Кендек әби үз эшен башкаргач миңа өйгә керергә рөхсәт бирелде. Эти шатлыгыннан кая барырга белмичә өй буйлап кызу-кызу йөри. Миңа әйтә: кызым, син хәзер бу дөньяда берүзең түгелсең, апаең да бар. Исемне дә Марска без эти белән куштык. Бер көнне ул мине тез очына утыртып киңәш йөртте: апаеңа нинди исем бирер идең, дип. Безгә этинең бик якын милиционер дусты Марс исемле улы белән кунакка киләдер ие. Ул бала миңа шундый матур күренәдер ие. Минем апаемда шундый сөйкемле, матур булыр дип уйлаганмындыр инде. Эти, Марс исемле булсын минем апаем, дидем. Эти берсүзсез килеште. Мин каян белим Марс ул борынгы грек алласының исеме икәнен. Андый планетада бар икән. Без әти белән дөрес куштык исемне - йолдыз исемен куштык. Марс этине хәтерләми, әлбәттә. Этидән ул ике яшендә аерылды. Этине сугышка озатканда без - Ялалетдин бабай, инәй, мин, Марс атка утырып ... тавы башына кадәр бардык. Ул шунда инәемә әйткән: Ничек кенә балаларны карарсың инде. Күрше...Ф..

ерып чыгар бу заманны, син ничек түзәрсең? Ярый әле безне өйле калдырды. Авылдан авылга күчеп йөргәнгә безнең үз йортыбыз да юк иде. Сугыш буласын бер ел алдан сизенеп безне Түбән Мактамага алып кайтты. Кечкенә булсада өй булдырды. Сугыштан килгән хатларын мин укыйдыр идем. Һәр хатында - утыныгыз бармы, ризыгыгыз бармы дип өзгәләнә иде. Апаең сөйләшәме, йөгерәме, шукмы дип һәр хатында безнең хәл-әһвәл белән кызыксынып торды. Шул хәтле күп хатлар яза иде ул, әллә көненә икешәр хат язды микән дип уйлыйм әле. Соңгы хатында Мәскәүдән 68 км янындабыз. Тиздән сугыш эченә керәбез дип язды. Монсы соңгы хат иде. Аннан хәбәре килде: Эзсез югалды. Инәй этинең үлүенә ышанмады. Ул аны шундый көтте. Капкалар шыгырдаса да, морҗадан бураннар уласада - ул сискәнеп, чү, бабалар, бәлки... Кайтмады эти. Марска ата назы кермәде. Ятим үсте апаем, тормышның бөтен ачысын татып. Инәем аны бик иркәли, сөя иде. Эти өлешедә булсын диптер инде. Марста бит армияда хезмәт иткән вакытында этинең вафат булган җирендә, Мәскәү округында була. Тик соңыннан гына бик күп еллер эзләтеп этинең һәлак булган җирен таптырды Марс. 68 нче км. Кабере дә уртак.

Эти исеменә Марс белән мин тап төшермәдек. Марс сабый чагыннан ир-ат эшләрен үз кулына алды. Укыды, эшләде, сабыр булды, горур булды. Армияга киткәнче яңа



www.tatars.com

өй салдык, аның түбәсен ул армиядан соң япты. Эти бүләк итеп калдырган нигезебездә йортыбыз янган кайгының ачылары инәемне сыгып төшерде. Күпме еллар ул монда этине көтте, безне үстерде. Аның этигә горурланып әйтерлек сүзләре бар иде: Шәехразый, кызың белән улыңны иң авыр елларда саклап кала алдым, үстердем. Кеше булдылар. Э син борчылган идең». Эгәр дә дин әйтүе буенча теге дөнья булса җаннары кавышкандыр инде».

( Здесь располагаются фотографии матери и отца, сестры, детские и армейские фотографии М.Залятова)

www.tatars.com